СОВЕТ ТЮКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
423732, село Тюково,
ул.Ленина, дом 61/2,
Тел. 3-44-61

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТҮКЕ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
423732, Түке авылы,
Ленин ур., 61/2 нче йорт.
Тел.3-44-61

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

19 декабрь 2024ел № 22

**"Актаныш муниципаль районы Түке авыл җирлеге Советының муниципаль вазыйфаларын биләүче затларга һәм Актаныш муниципаль районы Туке авыл җирлеге Башкарма комитетының муниципаль хезмәткәрләренә премияләр бирү һәм башка өстәмә түләүләр турында Нигезләмә хакындагы" Актаныш муниципаль районы Туке авыл җирлеге Советының 24.05.2023 ел, № 9 карарына үзгәрешләр кертү турында**

Актаныш муниципаль районы Туке авыл җирлеге Советының муниципаль вазыйфаларын биләүче затларга һәм Актаныш муниципаль районы Туке авыл җирлеге Башкарма комитетының муниципаль хезмәткәрләренә социаль гарантияләрне тәэмин итү, хезмәт өчен түләүне тәртипкә китерү һәм камилләштерү, аларның һөнәри хезмәт эшчәнлеген стимуллаштыру максатларында, Актаныш муниципаль районы Туке авыл җирлеге Советы карар итте:

1. "Актаныш муниципаль районы Туке авыл җирлеге Советының муниципаль вазыйфаларын биләүче затларга һәм Актаныш муниципаль районы Туке авыл җирлеге Башкарма комитетының муниципаль хезмәткәрләренә премияләр бирү һәм башка өстәмә түләүләр турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 1 бүлекнең 1.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

«1.1.Муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның, муниципаль хезмәткәрләрнең эшчәнлек нәтиҗәлелеген, җирле үзидарә органнарына йөкләнгән вәкаләтләрне үтәү өчен аларның җаваплылык дәрәҗәсен арттыру, башкарыла торган бурычларның сыйфатын күтәрү, вазыйфаи инструкциядә каралган вазыйфаи бурычларны вакытында һәм намуслы үтәү максатларында муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга, муниципаль хезмәткәрләргә премияләр түләнә:

- ярты еллык өчен эш йомгаклары буенча премия (алда-ярты еллык премия)
- Татарстан Республикасы көненә, җирле үзидарә көненә багышланган.

1.2. «4. Ярты еллык премия» бүлеген өстәргә кушымта нигезендә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында авыл җирлекләре бүлегендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Актаныш муниципаль районы
Туке авыл җирлеге Совет рәисе Р.М.Нуртдинов

Актаныш муниципаль районы Туке авыл җирлеге Советының «19»12.2024 22 карарына 1 нче кушымта

«4. Ярты еллык премия

4.1. Актаныш муниципаль районы Туке авыл җирлеге Советының муниципаль вазыйфаларын биләүче затларга һәм Актаныш муниципаль районы Туке авыл җирлеге Башкарма комитетының муниципаль хезмәткәрләренә, муниципаль хезмәткәрләр өчен акчалата түләү һәм муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар өчен бүләкләү күләмендә ярты еллык премияләр түләнә.

2.2. Муниципаль хезмәткәрләргә, муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга ярты еллык премияләр кими:

- билгеләнгән күләмнең 10% на - җирлек башлыгы, җирле үзидарә органы җитәкчесе тарафыннан гамәлдәге законнар нигезендә үз вәкаләтләре кысаларында бирелгән йөкләмәләрне вакытында һәм сыйфатсыз үтәгән өчен;

- билгеләнгән күләмнең 15% на - муниципаль программаларны үтәүчеләргә һәм региональ һәм федераль программаларны гамәлгә ашыру өчен җаваплыларга программаны яисә аның аерым чараларын вакытында һәм сыйфатсыз гамәлгә ашырган өчен, алар район бюджетының программаны гамәлгә ашыруга юнәлтелгән акчаларын нәтиҗәле һәм максатчан файдалануны тәэмин итмәгән өчен;

- билгеләнгән күләмнең 25% на - җирлек башлыгы, җирлек башкарма комитеты җитәкчесенең гамәлдәге закон нигезендә үз вәкаләтләре кысаларында бирелгән ашыгыч һәм аеруча мөһим беркетмә йөкләмәләрен сыйфатсыз үтәгән өчен;

- билгеләнгән күләмнең 10% на -гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау сроклары үтәлмәгәндә, шул исәптән башка учреждениеләрдән, оешмалардан килгән мөрәҗәгатьләр буенча, хезмәт документлары белән эшләү тәртибе бозылганда;

- билгеләнгән күләмнең 15% на - бер дисциплинар җәза булганда;

- билгеләнгән күләмнең 25% на - ике дисциплинар җәза булганда;

- билгеләнгән күләмнең 20% на - хезмәтне саклау һәм техника куркынычсызлыгы, янгын куркынычсызлыгы таләпләрен үтәмәгән өчен;

- билгеләнгән күләмнең 20% на - хезмәт дисциплинасын бозган өчен, эш вакыты режимы өлешендә, бер ай эчендә, нигезле сәбәпләрсез, һәркайсы 10 минуттан артык дәвам иткән эшкә икедән артык соңга калу теркәлгән очракта.

2.3. Ярты еллык премияләр түләнми:

- 3 һәм аннан күбрәк документны (мөрәҗәгатьләрне, хатларны)карау сроклары бозылган очракта;

- квартал дәвамында җирлек башлыгы, җирле үзидарә органы җитәкчесенең 3 һәм аннан күбрәк беркетмә йөкләмәләрен үтәмәү яисә тиешенчә үтәмәү;

- муниципаль мөлкәткә милекне юкка чыгармаган матди зыян китерү;

- вазыйфаи бурычларын үтәгәндә билгеле булган хезмәт мәгълүматын ачу;

- муниципаль хезмәт узуга бәйле чикләүләрне һәм тыюларны, хезмәттә үз-үзеңне тоту бурычларын һәм кагыйдәләрен, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки җайга салу турындагы таләпләрне үтәмәү, коррупциягә каршы көрәш максатларында билгеләнгән бурычларны үтәмәү.